СОВЕТ БУРНАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БОРНАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«28» апреля 2023 г. №79

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеш кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Авыл җирлегенә җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча вәкаләтләр тапшыру турында" Татарстан Республикасы Балтач район Советының 23.03.2023ел, 176 нчы номерлы карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы 2013елның 31 маендагы 82 нче номерлы Борнак авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре”нә (13.12.2016 №39; от 21.06.2018 №80; от 29.08.2018 №85; от 12.11.2021 №37 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 35.1 маддәсенең Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы Ж-1 өлешенең Кучемсез милекнең рөхсәт ителгән төп төрләре пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси торак төзелеше өчен.

-Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге)".

1.2. 35.1 маддәсенең Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы Ж-1 өлешенең Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре пунктчасында «яшелчә бакчасы» сүзен төшереп калдырырга.

1.3. 35.1 маддәсенең Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы Ж-1 өлешенең Файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төрләре пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Гаражларны үз ихтыяҗлары өчен урнаштыру.

-Бакчачылык алып бару».

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 12 ноябрендәге 36 нчы номерлы Борнак авыл җирлеге Советы карарының 1 пункты 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. 35.1 маддәсенең Ж-1 өлешендә Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы авыл җирлекләрендә гражданнарга бирелә торган җир участокларының минималь күләмен билгеләргә:

- шәхси торак төзелеше өчен - 1000 кв.м;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 1000 кв.м;
- бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек өчен - 100 кв.м.».

Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы гражданнарга авыл җирлекләрендә бирелә торган җир кишәрлекләренең максималь күләмнәрен билгеләргә:
- шәхси торак төзелеше өчен - 4000 кв.м;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 4000 кв.м;

Җир кишәрлекләренең билгеләнгән чик (минималь) күләмнәре түбәндәге очракларда кулланылмый:

- хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән ясалган һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген җирлектә формалаштыру мөмкинлеге булмау;

- ике һәм аннан күбрәк җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге барлыкка китерү;

- гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмау;

- территорияне планлаштыру документларында башкасы билгеләнгән булса;

- әлеге карар кабул ителгәнчегә кадәр кадастр исәбенә куелган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның юкка чыккан төрен билгеләү.».

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлегендә төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге башлыгы: Ш.М.Хабибуллин